### *Мәчеттә укулар бара*



Быел без мәчеттә балалар өчен махсус уткәрелә торган дәресләргә йөри башладык. Бу дәресләргә башлангыч һәм 5 нче сыйныф укучылары йөри. Мәчеткә барлыгы 15 укучы җыелабыз. Безне монда Гөлүсә, Алмира һәм Сафия апалар укыта. Дәресләрдә Ислам дине нигезләрен, гарәпчә укуырга һәм язарга өйрәнәбез. Әле уку-язудан тыш төрле кызыклы эшләр дә эшлибез. Тәнәфес вакытында апалар безне тәмле ризыклар белән чәй эчерәләр.

Мәчеттәге дәресләрдән без тынычланып һәм ял итеп кайтабыз. Бу укуны алып барган апаларыга рәхмәт кенә әйтәсебез килә. Мәчеттә алган белемнәрне беркайчан да онытмабыз.

***Абдулла Хәбибрахманов, IV сыйныф укучысы***

***/Безнең спорт/***



7 нче гыйнвар көнне Аксубай яшьләр үзәгендә ир-егетләр арасында Татарстанның физкультура алдынгысы В.А.Горбунов истәлегенә багышланган ачык шахмат турниры уздырылды. Турнир алдыннан В.А.Горбуновның улы Геннадий Валерьевич, көннәр салкын булуга карамастан, әтисен олылап килгән барлык кунакларга рәхмәт сүзләрен җиткерде. Уенчылар арасында Казан һәм Саба кунаклары да бар иде. Уеннар бик кызу барды. Турнирда укучыбыз **Фаил Гафиятуллин** беренчелекне бирмәде. Икенче урында **Ирек Сабиров (Саба)**, өченче урынны **Тимур Магизов яулады (Казан)**. Җиңүчеләр грамоталар һәм акчалата приз белән бүләкләнде.

***/Чал тарихта эзле без!/***

### *"Такталы" атамасы турында*

"Мәктәп хәбәрчесе"нең алдагы саннарында Түбән Майна һәм Әдәмсуы авылларының исемнәре турында мәкаләләр урнаштырган идек. Бу санда **Такталы** авылы исеменең килеп чыгышын карап үтербез.



Такталы авылы 1750 нче еллар тирәсендә барлыкка килә. Аңа Иске Татар Әдәмсуы авылыннан аерылып чыккан 30 гаилә нигез сала. Бу күченүнең сәбәбе төгәл билгеле түгел. Моңа ул елларда бик актив алып барылган көчләп чукындырудан качырга тырышу, яисә эшкәртелә торган җирләргә якынрак урнашу китергән булырга мөмкин. Совет чорына кадәрге документларда авыл **"Новопоселённая Тахтала"** дигән исем белән китерелә. Бу исем Такталының тирә-яктагы башка авыллар белән чагыштырганда соңрак нигезләнүен дәлилли.

Авылның исеменә килгәндә, ул аның аркылы агучы елга атамасыннан күчкән. Такталы елгасы Әдәмсуы авылы җирләрен тасвирлаган документларда әле XVIII гасыр башында да телгә алына. Риваять буенча, елганың бу исеме аның аркылы такта куеп та чыгып булганлыктан кушылган. "Такталы" исемен йөрткән авыллар Болгар ягында да бар. Болар Спас районындагы Татар Такталысы һәм Әлки районына кергән Иске һәм Яңа Такталы дигән чуаш авыллары. Аларның исемнәре дә ул тирәдән агучы елга атамасыннан күчкән.

Элек безнең тирәдә "Такталы" исемен йөрткән тагын бер авыл булган. Бу авыл 1770 нче елларда Иске Татар Әдәмсуыннан аерылып чыккан морза Булаевлар нәселе вәкилләре тарафыннан нигезләнә. Аңа **"Такталы Тамагы" ("Усть Тахтала")** дигән исем Такталы һәм Әдәмсуы елгаларының кушылган җирдә урнашуыннан бирелгән. Ул җиргә беренче килеп төпләнгән кеше исеменнән авыл "Собханкол" дип тә аталган. 1858 нче елгы мәгълүматлар буенча бу авылда 34 йортт 184 кеше яшәгән. Аның үзенең мәчете дә булган. Такталы тамагындагы авыл 1870-1890 нчы елларга яшәүдән туктый. Шуннан соң аның халкы яңадан Иске Татар Әдәмсуына кушыла. Авылның 1870 нче еллар уртасында оешкан икенче мәхәлләсендә нигездә Такталы тамагыннан күченгән кешеләр урнашкан булырга тиеш.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы,***
***тарих фәннәре кандидаты***


**Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе**
**Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина**
**Редколлегия әгъзалары: Әминә Туктамышева, Виктория Нукина, Зөлфирә Сафиуллина**



# Мәктәп хәбәрчесе

**№1**
**(№42)**
**гыйнвар**
**2023 ел**

***Түбән Майна урта мәктәбе гәзите***



**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**


***Бу санны башлангыч сыйныфлар әзерләде***

***/Мөхәррир минбәре/***

### *2023 – укытучылар һәм остазлар елы*




Быелгы ел ил күләмендә укытучылар һәм остазлар елы дип игълан ителде. Бу карар укытучыларның югары дәрәҗәсен, алар башкарган эшнең мөһимлеген тану турында сөйли. Ил җитәкчелеге тарафыннан мөгаллимнәр алдында куелган йөкләмәләр укытучы һөнәренең абруен күтәрүгә, гомерләрен халык мәгарифенә багышлаган шәхесләргә хөрмәт һәм игътибар арттыруга юнәлтелгән.

Һәр кешенең тормыш юлын башлаганда аңа юнәлеш биргән, гомер барышында маяк булып торган остазы бар. Әлеге хөрмәтле затлар һәрвакыт җылылык белән искә алына. Алар булмаса, аяк баскан эзебез ныклы булмас иде. Яшь буынның, һәм гомумән халкыбызның киләчәге – укытучы кулында, аның алтын йөрәгендә. Шуңа күрә кеше тормышында укытучының роле һәм урыны бәяләп бетергесез.

Укытучының чын мәгънәсендә остаз дәрәҗәсенә күтәрелүе җиңел эш түгел. Моның өчен һөнәри осталыгыңны арттыру юнәлешендә бик күп эшләү, шәхси сыйфатларыңны башкалар өчен үрнәк булырлык дәрәҗәгә җиткерү, һәм иң мөһиме – балаларны чын күңелдән ярату таләп ителә. Зур хәрефләр белән язылырлык УКЫТУЧЫ исемен күтәрү – зур бер батырлык дип әйтер идем мин. Чөнки, бары тик көчле рухлы, сабыр кеше генә ОСТАЗ исеменә лаек була аладыр. Моның өчен үз белемнәреңне башкаларга бирә белергә, авырлыкларны җиңеләйтә, бала күңелен аңлау сәләтенә ия булырга кирәк. Мөгаллим булу – ул һөнәр генә түгел, ә кешенең язмышы буларак язылган. "*Мин сезнең алдыгызда түбәнчелек белән баш ияр идем*" дигән бөек рус шагыйре Н.А.Некрасов.

Хәзерге заман балалары үткән буыннардан бик күпкә аерыла. Алар бик күп белә, акыллы техникага, мәгълүмат чараларына нык бәйләнгән. Менә шундый шартларда заман белән бергә атлап, укытуның тагын да мавыктыргычрак юлларын табып белем бирергә кирәк. Аларны имтиханнарга гына түгел, башка ярышларга да әзерләргә, сәхнәдә дә үстерергә кирәк. Гомумән алганда, мөгаллимнәрдән үз шәкертләрен бүгенге бик тиз үзгәрүчән һәм катлаулы тормыш шартларында югалып калмыйча үз юлын табарлык дәрәҗәсенә җиткерү таләп ителә. Шул ук вакытта, мәктәп диварлары эчендә генә түгел, урамда да, кибеттә дә, хәтта үз гаиләңдә дә укытучы булып кала белергә кирәк. Чын укытучы – балаларның аз гына уңышына да сөенүче икенче әти-әни кебек. Чәчү вакытында мең кайгырса, уңыш җыйганда аннан да күбрәк шатлана. Укудан тыш вакытта, хәтта укучылары мәктәпне тәмамлап киткәч тә, аларны күз уңыннан ычкындырмаска тырыша, хәлләрен сорашмыйча йөрәге түзми.

Еллар нинди исем белән аталмасын, чын мөгаллим һәрвакыт УКЫТУЧЫ һәм ОСТАЗ булып калачак. Һөнәренә багышланган елмы, башкасымы – укытучыга барыбер үз бурычларын үтәргә. Чөнки аның максаты – балаларга ныклы белем һәм тәрбия бирүне һәрдаим югары дәрәҗәдә алып бару. Бүген парталар артында утыручы балаларыбыз иртәгесе көндә дөньяны тотучылар булачак. Укытучы булып кайткан укучыларыбызны да күрергә язсын дигән теләктә калабыз.

***Фәнүзә Гафиятуллина, газетаның баш мөхәррире***

***/Мәктәп тормышы/***

### *Кабатлау – КВН формасында*



Кабатлау-материалны истә калдыру һәм үзләштерүнең төп шартларының берсе булып тора. Кабатлауның файдасына ачык мисал булып кечкенә балага яңа сүз өйрәтүне алып була. Зур кеше бала сүзне исендә калдырганчы берничә кат кабатлый. Шулай ук баланы тәрбиягә, әдәпкә өйрәткән вакытта да без бер үк нәрсәләрне һәркөнне диярлек кабатлыйбыз: уенчыкларыңны җыеп куй, киемнәреңне урынына эл һәм башкалар. Бары тик кабатлау юлы белән генә уңай нәтиҗәгә ирешеп була.

Укытучыларның һәм ата-аналарның төп бурычы – балага белемен тирәнтен үзләштерүдә ярдәм итү. Бу эштә төп инструментларның берсе булып кабатлау тора.

***(Дәвамы 2 нче биттә)***

Кабатлау файдасына түбәндәге аргументларны карап китик:
- хәтер үсә һәм иң кирәкле мәгълүмәт ныграк истә кала;
- игътибар өйрәнелә торган объектка юнәлтелә, аңлашылмыйча калган урыннар ачыклана;
- белемнәр тирәнәя һәм тикшерелә, күнекмәләр автоматизмга җиткерелә;
- тупланган мәгълүмәт системалаштырыла.

Менә шуларның барысын да истә тотып, каникулдан килгәннән соң, башлангыч сыйныф укучылары арасында әйләнә-тирә предметыннан гомуми кабатлау дәресе булып узды. Дәрес интерактив КВН формасында үтте. Укучылар ике командага бүленеп ярыштылар. Уен барышында беренче яртыеллыкта алынган белемнәр тирәнтен яңартылды. Балларның югарылыгына карап, төрле авырлыктагы сорауларны укучылар үз мөмкинлекләренә карап сайлап алдылар. Уендагы сорауларның барысы да балаларның логик фикерләвен үстерүгә юнәлтелгән иде. Әлбәттә, ребуслар һәм башваткычлар да читтә калмады.

Шундый форматта узган кабатлау дәресе укучыларга аеруча да ошады. Ахырдан һәр балага татлы бүләк өләшенде.

***Рузилә Хәйруллина, башлангыч сыйныф укытучысы***



## *Блокада икмәге*

27 гыйнвар көнне Ленинград шәһәре блокадасының тәмамлануына 79 ел тулды. Бу көнне ил күләмендә Бөек Ватан сугышы барышында оборона һәм Ленинград блокадасы тарихына багышланган "Блокада икмәге" Бөтенроссия Хәтер акциясе уза. Бу акция дошман гаскәрләре тарафыннан блокадаланган Ленинград халкының аяныч язмышын, ике елдан артык үзләренең һәм якыннарының тормышы өчен көрәшкән тыныч халыкның батырлыгын искә төшерүгә юнәлдерелгән.

Безнең мәктәп тә әлеге бу акциягә кушылды. Әлеге чараның максаты – мәктәп укучыларында патриотизм, Ватан өчен горурлык хисен формалаштыру, Ленинградны саклаучыларның батырлыгы мисалында безнең халык өчен горурлык хисе тәрбияләү. «Блокада икмәге» Бөтенроссия акциясенең төп символы — 125 грамм авырлыктагы икмәк кисәге. Ленинград блокадасының иң авыр чорында нәкъ менә шундый минималь икмәк бирү нормасы куелган була. Балалар бу икмәкнең составы турында белделәр. Блокададагы Ленинградта яшәүчеләрнең истәлекләре турында видеоролик карадылар. Соңыннан һәйкәл янына чәчәкләр куелды. Сугышта вафат булган батырларны бер минут тынлык белән искә алдык.

***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныф укытучысы***

## *Чаңгыда йөрүнең файдасы турында*



Чаңгы спорты – иң массакүләм, кызыклы һәм файдалы спорт төрләренең берсе. Чаңгыда йөргән вакытта иң беренче чиратта бала салкын саф һава белән сулый. Бу исә, организмны ныгыта, көч бирә, чыдамлыкны арттыра, сулыш алу һәм кан әйләнешен көчәйтә. Вакытын саф һавада үткәргән бала сәламәт һәм нык иммунитетлы булып үсә, авыруларга бирешми торган була. Чаңгыда шуганда кешенең мускуллары ныгый, чөнки шуу барышында гәүдәнең барлык өлешләре, бигрәк тә аяклар һәм куллар хәрәкәткә килә. Чаңгыда йөрү шулай ук балаларның аякларын дөрес формалаштырырга зур йогынты ясый. Яссы аякның (плоскостопие) үсешен кисәтергә, хәрәкәтләрне координацияләргә ярдәм итә.

Чаңгыда йөрү балаларда әхләкый-ихтыяри сыйфатлар тәрбияләргә дә булыша: кыюлык, тәвәккәллек тәрбияли, авырлыкларны һәм киртәләрне җиңәргә өйрәтә, сабырлык формалаштыра.

Менә шуларның барысын да истә тотып, матур көннәрне без балалар белән физик тәрбия дәресләрен чаңгы уеннарына багышлыйбыз. Укучыларыбыз бер ялкауланмыйча кросс чабалар, тауда да оста шуалар, таудан менү ысулларының барысын да яхшы үзләштерәләр. Шулай ук чаңгылы күмәк уеннарда да актив катнашалар.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә була: әгәр сез дә чаңгы шуу белән шөгыльләнергә уйласагыз, һичшиксез, отачаксыз! Чаңгы спорты – менә дигән файдалы вакыт уздыру чарасы. Әлеге спорт төре белән шөгыльләнгәндә, сиңа ничә яшь булуы да мөһим түгел. Шулай ук, чаңгы шууны үз гаиләгезгә матур бер гадәт итеп тә кертеп җибәрә аласыз. Һәм шуны истә тотыгыз: чаңгы белән шөгыльләнә башлагач, туктау бик кыен булырга мөмкин!

***Сафия Хәбибрахманова, башлангыч сыйныфлар укытучысы***



## *Кышкы уеннар*

***/Укучылар иҗаты/***

Кыш көне уеннарның нindиен генә уйнамыйсың! Күп вакытта чаңгыда узышасың. Җылы көндә кар бабай тәгәрәтәсең. Салкын көндә окоп казыйсың. Ләкин быел кар бик аз яуды һәм окоплар казып булмый, кызганычка каршы.

Мин үзем таудан шуарга бик яратам. Мәктәптә үк дусларым белән тауга төшәргә сөйләшеп кайтам. Мәктәптән кайтканнан соң җыелышып Чирмешәнгә төшәбез. Малайлар төрле-төрле чаналар алып килә. Тауга менәргә генә уңайсызрак, төшүләре исә бигрәк кызык. Җилдертеп төшеп китәсең... и рәхәт тә соң шул вакытларда. Бер-бер артлы чылбыр ясап шуулары бигрәк тә кызык. Чана шуып арыганнан соң бергәләшеп өйләргә таралабыз.

Мин кышкы уеннарны бик теләп уйныйм, сезгә дә салкыннан куркып өйдә утырмаска киңәш итәм.

***Инсаф Закиров, II сыйныф укучысы***

## *Кышкы авылым*

Туган ягыбызга кабаттан кар бураннарын туздырып кыш килде. Ул барлык җирне дә ак юрганы белән каплап алды. Күпчелек хайваннар шул юрган астында язга кадәр тирән йокыга талды.

Кыш ул үзенең ак карлары белән матур. Әкрен генә яуган кар бөртекләрен күзәтүе нинди рәхәт! Әгәр без аларны җентекләп карасак, һәр кар бөртегенең үзенә генә хас булган бизәге барлыгын күрәбез. Алар күктән йолдызлар яңгыры сыман явалар. Әкрен генә төшәләр дә, җиргә яталар. Кояшлы көннәрне алар җирдә энҗе бөртекләредәй җемелдиләр. Салкын көннәрне исә кар адым баскан саен матур итеп шыгырдый. Салкын көннәр табигатьне аеруча бизи, чөнки барлык җирне бәс сара. Андый вакытта урамда йөрүләре аеруча рәхәт инде. Үзеңне әкияттәгедәй хис итәсең.

Кышны кешеләр төрле сыйфатлары өчен яраталар. Ә мин бу ел фасылын аклыгы,уеннарның кызыклыгы өчен яратам.

***Камалов Илнур, II сыйныф укучысы***

## *Минем кышкы ялларым*

Мәктәптә яңа ел бәйрәмен күңелле генә үткәргәннән соң, көтеп алган кышкы каникуллар башланды. Каникулның беренче көнендә үк мин Алабуга шәһәренә кунакка киттем. Анда мин туган апаларымда кунакта булдым. Апа мине һәр көнне көндезге мөселман лагерына йөртте. Лагерьның һәр көне бик күңелле узды. Анда безгә тәрбия, дин дәресләре үткәрделәр, кул эшләре белән шөгыльләндек. Шулай ук кызыклы уеннар уйнадык. Мин монда үземә яңа дуслар да табып өлгердем.

Лагерьдан буш вакытта туган апам безне Алабуга шәһәре белән таныштырды. Без бөек рәссам Шишкинның музеенда булдык. Үзем рәсем ясарга бик яратканга, бу музей миңа бик охшады. Минем кышкы каникулым бик кызыклы һәм файдалы үтте.

***Айшә Гәлиәскәрова, II сыйныф укучысы***

## *Эшләп ашагач тәмле була*



Минем яраткан дәресләремнең берсе – хезмәт дәресе. Бу дәрестә без төрле матур әйберләр ясыйбыз. Ә аена бер тапкыр берәр яраткан ризыгыбызны әзерләргә өйрәнәбез.

Узган айда без япон халык ризыгы – роллы әзерләү серләрен өйрәндек. Аның өчен иң беренче чиратта дөге пешерергә кирәк. Анысын безгә апалар пешереп бирде. Шуннан соң нори битенә дөгене җәябез, урта бер җиренә эремчекле сырны сөртеп чыгабыз һәм сыр янына үзебезнең калган ризыкларны тезәбез. Без тозлы форель балыгы һәм кыяр кулландык. Шуннан соң роллыбызны тыгыз итеп төрәбез һәм кечкенә кисәкләргә кисеп чыгабыз.

Ризыкны әзерләп бетергәч, без бергәләп ашыйбыз. Үзебез ясаган роллалар кибетнекеннән күпкә тәмлерәк була. “Үз кулыгыз белән ясаганга “, – дип әйтәләр укытучы апалар. Чыннан да үзең пешергән ризык тәмле дә , бәрәкәтле дә була икән ул. Менә шулай кызык һәм файдалы үтә безнең хезмәт дәресләре.

***Асия Нурматова, III сыйныф укучысы***

***/Котлыйбыз!/***



Гыйнвар аенда дөньяга килгән дусларыбыз – бакча төркеменнән Хәйруллин Мансурны, укучылардан Залиев Илфирне, Закирова Ләйсәне, Җамалетдинова Инзилә, Хәбибрахманова Мәрьямны, Камалов Илдусларны туган көннәре белән котлыйбыз. Аларга укуларында уңышлар, ныклы сәламәтлек телибез.

Мәктәп хезмәткәрләреннән математика укытучысы Зарипов Фәнил абыйны, Хөснуллин Фәнис абыйларны, бакча хезмәткәрләре Бәширова Алмираны, Сәгдиева Рәмзия апаларны гомер бәйрәмнәре белән котлыйбыз. Аларга ныклы сәламәтлек, озын гомер, гаилә иминлеге теләп калабыз.